**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

**2020 елның 22 июня** **№ 258**

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы карарының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору хакында (2014 елның 22 сентябрендәге 240 номерлы, 2015 елның 20 октябрендәге 16 номерлы, 2018 елның 12 ноябрендәге 164 номерлы, 2019 елның 16 октябрендәге 221 номерлы карарлар редакциясендә)**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2020 елда Федераль бюджетны үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2019 елның 12 ноябрендәге 103-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 1 апрелендәге 103-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында» 2013 елның 18 ноябрендәге 201 номерлы карарының 38 статьясындагы 1 пунктының, 26 статьясындагы 1 пунктының, 34 статьясындагы 1 абзацының, 37 статьясындагы 3 пунктының (бюджет үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмәләр әзерләү сроклары өлешендә), 38 статьясындагы 1 пунктының (2018 елның 12 ноябрендәге 164 номерлы, 2019 елның 16 октябрендәге 221 номерлы карарлар редакциясендә) гамәлдә булуын 2021 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Кама Тамагы муниципаль**
**районы Башлыгы,**
**Кама Тамагы муниципаль**
**районы Советы рәисе** **Н.А. Вазыйхов**